СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы карары**

**« 01 » июль 2024г** **№ 98**

**«Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Яңасала авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 04 июньдәге 97 номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында Муниципаль хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 майдагы 300 номерлы карары белән,Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге уставы нигезендә, Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Яңасала авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында»2024 елның 04 июньдәге 97 номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 Пункт Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга хезмәт хакы түләү турында Нигезләмәне (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Яңасала авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфаи окладьы күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициенты түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Коэффициент |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе | 1,37 |
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 1,33 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч<br>2 категорияле белгеч<br>белгеч | 1,00 |

2. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) Җирлекләр бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И.Сафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003024